Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Кама-Исмәгыйль авыл Советы

КАРАРЫ

23 апрель 2024 ел № 90

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге Уставының XIV бүлеге, 2023 елның 23 ноябрендә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 7 августындагы күрсәтмәсен карап № 02-08-02/850

Кама-Исмәгыйль авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге Уставына (Кама-Исмәгыйль авыл Советның 2012 елның 5 июлендәге 35 номерлы, 2013 елның 28 августындагы 65 номерлы, 2014 елның 19 декабрендәге 109 номерлы, 2016 елның 12 маендагы 20 номерлы, 2017 елның 12 апрелендәге 30 номерлы, 2018 елның 20 июлендәге 44 номерлы , 2019 елның 19 маендагы 64 номерлы, 2020 елның 12 маендагы 82 номерлы, 2021 елның 27 сентябрендәге 26 номерлы, 2023 елның 19 маендагы 74 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымта нигезендә түбәндәге үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.
3. Әлеге карарны Әлмәт районы, Кама-Исмәгыйль авылы, Ленин урамы, 92а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясының 8 өлешенә ярашлы рәвештә үз көченә керә.
5. Бу карарның үтәлешен контрольдә тоту Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Кама-Исмәгыйль
авыл җирлеге башлыгы А.З. Шайдуллина

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКА МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «КАМА-ИСМАГИЛОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ОГРН 1021601628465
Р05-10980/16
КАМА-ИСМАГИЛОВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ СОВЕТ
ИНН 1607002226
КПП 164401001